

Ләмберәдә яшәvче Халидә Сенәтулла кызы Мариновага 92 яшь, дип яза «Призыв» газетасы. Ул кvп фатирлы йортнын бер бvлмәле квартирында кvптән берvзе яши; туганнарыннан беркем дә исән калмаган инде. Шул ук вакытта, олкән яшьтәге ханым vз тормышыннан зарланмый. Киресенчә, һәр киләсе конгә соенеп бетә алмый. Әле кыш килеп житмәгән, ә ул инде киләсе яз турында уйлый: хәзер vк нинди яшелчә орлыкларын сатып алырга кирәклеге турында планнар този.Ә сонрак, ике сутый бакчасында нәрсә утыртачагын фатир тәрәзәсеннән карап хыяллана.      - Олы яшемдә булуга карамастан, барлык эшләрне vзем башкарам, - дип белдерде шушы коннәрдә игелекле карчык. - Мин бит vз бакчамда ярдәмчеләрсез эшлим. Яшелчәне vзем утыртам, тvтәлләрдәге чvп vләнне утыйм, vсемлекләргә су сибәм. Үз бәрәнгем, кишерем, чогендерем, суганым…
Бу гажәеп ханым ой эшләрен дә мостәкыйль башкара - жыештыра, юа, аш-су әзерли, икән. Кибетләргә дә икмәк яки сот артыннан vзе йори. Ә тагын, эчv һәм ашарга әзерләv очен, жәмәгать коесыннан биш литрлы пластик савытка тутырып, суны да vзе алып кайта. Фатирда краннан ага торган сунын сыйфаты начар, ди.
Халидә Сенәтулла кызына кvптән тvгел «Сугыш балалары» дигән истәлек медальне ойдә тапшырганнар. Бу ана бик ошаган. Ә нигә vз сәламәтлегенне куркыныч астына куярга, - ди ул, хәзер кvпләр, пандемия аркасында, артык тапкыр урамга чыгудан да курка бит?
- Мин бvләктән бик канәгать. Боек Ватан сугышы вакытындагы хезмәтемне искә тошерvләре һәм бәяләvләре бик кvнелле, - ди озын гомерле ханым. - Ий, без ул вакытта ничек эшләдек, ничек эшләдек! Сугыш башланганда мина уноч яшь кенә (1928 елда тудым) иде бит! Әтием белән әниемнен ундvрт баласы иде; мин - ин кечкенәләре, ягъни исәбе буенча ундvртенчесе. Менә кvпме иде! Ә хәзер минем беркемем дә калмады – апаларым да, абыйларым да бакыйлыкка кvчтеләр инде. Ундvрттән берәv - берvзем генә калдым.
Халидә Сенәтулла кызы, кырыгынчы елларны искә алып, ул вакытта авылларда балалар тиешледән тизрәк vстеләр, ди. Олкәнәю теләге булганга тvгел, ә тормыш таләп иткәнгә. Бигрәк тә кvп балалы гаиләләргә исән калу авыр булды. Кешеләр кон саен, ботенләй аяктан егылмас очен, авызга нинди аш бортеге салырга - ашарга, дип уйладылар шул вакыт. Ә тагын – коне-тоне эшләделәр. Безнен героебыз да туган колхозына ярдәм

итәргә тырышкан: басу-кырларда, токларда яшvсмер буларак башкарган эшләрен санап бетерерлек тvгел... Авыр булган, тик ул вакытта беркем дә авырлыкларга зарланмаган. Барысы да дошманны тиз арада жинv, фронттан якын кешеләренен ойләренә исән-сау кайтулары турында хыялланганнар.
- Кайвакыт балалар мәктәпкә дә йормә-де, - дип сvзен дәвам итә Х.С.Маринова. - Монын сәбәбе берничә иде: фронт очен эшләргә һәм олкәннәргә хужалык буенча ярдәм итәргә кирәк иде. Кышларын мәктәптә бик салкын була иде, хәтта чернила тунды. Кәгазь житмәгәнгә, сары газеталарнын язудан чиста калган урыннарына яздык... Шулай, булдыра алганча, яшәдек тә инде. Шул чакта ин моһиме - рухны югалтмау. Һәм, әлбәттә, кешеләр бер-берсенә ярдәм иттеләр. Бу да кvпләрне хәтта vлемнән дә коткарды…
Әйтеп китәргә кирәк, Халидә Сенәтулла кызына «Сугыш балалары» медален Ләмберә муниципаль районы ветераннар Советы рәисе урынбасары Рафаэль Кряков тапшырган. Бу конне тагын биш Ләмберә авылы тыл хезмәтчәне дә шундый ук бvләкне алганнар. Алар - Г.У.Казакова, М.Н.Королева, М.Я.Шитова, Ш.С.Сюбаев һәм Г.Х.Курмакаева.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**